# КАРАР

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«10» апрель 2024 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрелендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 10.11.2023 ел, № 5 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле торак пунктында гражданнар җыены 10.11.2023 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә килешәсезме:

2024 елда Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 1000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итү;

- Киекле торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонты (коелган асфальт);

Киекле торак пунктында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

Киекле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар төзү, Киекле торак пунктында традицион җирләү урыннарын 3 данә күләмендә төзекләндерү;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм Киекле торак пунктында аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

жыенда катнашучы  сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 698 кеше кертелгән, жыенда тавыш бирүдә 389 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 368 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 21 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле  авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 10.11.2023 ел, № 5 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Киекле торак пунктында гражданнар җыены 10.11.2023 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә килешәсезме:

2024 елда Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 1000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итү;

- Киекле торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонты (коелган асфальт);

Киекле торак пунктында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

Киекле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар төзү, Киекле торак пунктында традицион җирләү урыннарын 3 данә күләмендә төзекләндерү;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм Киекле торак пунктында аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат

муниципаль районының Киекле  авыл җирлеге Киекле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова